| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ
« 16 » июль 2024 ел

КАРАР
№ 102

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советының 15.12.2023 елның 92 нче номерлы «2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге бюджеты турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башкарма комитетының баш бухгалтеры Алпутина Л.В. мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советы бюджетына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Кече Лызи авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советының 15.12.2023 елдан 92нче номерлы «2024 елга һәм 2025-2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге бюджеты турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

1. 1нче статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 6 766,105 мең сум күләмендә; бюджет керемнәре күләмен гражданнарның үзара салымыннан алынган өстәмә акчалар исәбеннән 388,2 мең сум күләмендә арттырырга;

2) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 6 766,105 мең сум итеп; бюджет чыгымнары күләмен өстәмә алынган керемнәр исәбеннән арттырырга.».

2. 1нче, 3 нче ,5 нче,7 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Кече Лызи авылы АҖ бинасы, Үзәк урамы 2нче йорт; Кече Лыза авылы мәдәният йорты, Үзәк урамы, 1 нче йорт; Югары Ушма авылы, Комаров урамы, 35 нче йорт.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге Советы рәисе А.С.Исмагилов